**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**

2020 ел, 30 апрель №290

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

"Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законы, муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы **к а р а р и т т е**:

1.«Татарстан Республикасы Апас муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының 2016 елның 9 февралендәге 19 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а)5.8 пунктының 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) коммерцияле яки коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә түбәндәге очраклардан тыш катнашырга:

сәяси партия идарәсендә, профсоюз органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә күчемсез мөлкәт милекчеләре гомуми җыелышында катнашу;

коммерциягә карамаган оешма идарәсендә (сәяси партия белән идарә итүдә катнашудан тыш) профсоюз органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтләренең съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында яллаучы вәкиленең Татарстан Республикасы законында билгеләнгән тәртиптә алынган рөхсәте белән катнашу;

Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә күрсәтү;

муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен йә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә муниципаль берәмлекнең идарә органнарында һәм Ревизия комиссиясендә, гамәлгә куючы (акционер) булган оешма мәнфәгатьләрен муниципаль берәмлек исеменнән берәмлек мәнфәгатьләрен күрсәтү;

федераль законнарда каралган башка очраклар.»;

б) 5.8 пунктнына түбәндәге эчтәлекле 3.1 пунктчасын өстәргә:

«3.1) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;»;

в) 18.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18.9. Әлеге Нигезләмәнең 6, 7 статьяларында һәм 17.2 пунктында каралган түләтүләр, муниципаль хезмәткәрнең вакытлыча эшкә сәләтсез булу чорын, отпускта булуын исәпкә алмыйча, коррупциячел хокук бозу турындагы мәгълүмат кергән көннән алып алты айдан да соңга калмыйча һәм коррупциячел хокук бозу кылган көннән өч елдан да соңга калмыйча кулланыла. Күрсәтелгән вакытта җинаять эше буенча эш вакыты кертелми.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Башлыгы урынбасары Л.Т.Хантимировка йөкләргә.

**Апас муниципаль районы Башлыгы**
**Апас муниципаль районы Советы Рәисе** **Р. Ф. Хисамутдинов**